| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРЛАТ АВЫЛЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01 февраль 2021ел** **№3**

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон», «Җирләү һәм җирләү эше турында "1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында" 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары» нигезендә, Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 февраленнән 1 нче һәм 2 нче кушымталарга карата Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе 6424,98 сумнан билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Норлат авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 31.01.2020 ел, №3 карарын 1 нче февраль 2021 елдан үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы информация сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, М. Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Идел Аръягы»үзәге бинасы) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Норлат
авыл җирлеге башлыгы И.М. Саттаров

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты 2021 елнын 01 феврале, №3 нче карарына 1 нче кушымта

01.02.2021елга ТР Яшел Үзән муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлеге хезмәтләренең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (берсум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3501,30 |
| 3. Үлүчене (мәетне) зиратка илтү | 997,40 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл жирлеге башкарма комитеты 2021 елнын 01 феврале. №3 нче карарына 2 нче кушымта

01.02.2021 елга ТР Яшел Үзән муниципаль районы Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлеге хезмәтләренең бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | **Хезмәт күрсәтү бәясе (берсум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне гыйбадәтләү | 618,59 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2882,71 |
| 4.Үлүчене (мәетне) зиратка китерү | 997,40 |
| 5.Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |